РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

## РЕШЕНИЕ / КАРАР

№ 24

2020 елның 23 марты

### Түбән Кама муниципаль районы Советының 2011 елның 22 декабрендә кабул ителгән 40 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милкенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 һәм 51 статьялары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2011 елның 22 декабрендә кабул ителгән 40 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милкенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 11.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11.9 Хуҗалык җәмгыятьләре идарәсе органнарында вәкил гамәлгә ашыра:
1) акционер хокуклары:
- үз компетенцияләренә караган барлык мәсьәләләр буенча акционерларның гомуми җыелышында катнашу;
- район бюджетына дивидендларның тулысынча һәм үз вакытында күчерелүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;
- җәмгыятьне гамәлдән чыгарган очракта, җәмгыять милкенең бер өлешен алуга;
- законнарда һәм (яки) җәмгыять уставында каралган башка хокуклар.
2) катнашучы хокуклары:
- җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында Законда һәм җәмгыять уставында билгеләнгән тәртиптә җәмгыять эшләре белән идарә итүдә катнашу;
- җәмгыять эшчәнлеге турында мәгълүмат алу, җәмгыятьнең уставында билгеләнгән тәртиптә аның бухгалтерия китаплары һәм башка документлар белән танышу;
- табыш бүлүдә катнашу;
- законда һәм җәмгыять уставында каралган тәртиптә әлеге җәмгыятьнең бер яки берничә катнашучысына яисә башка затка җәмгыятьнең устав капиталындагы катнашучы өлешен яки өлешнең бер өлешен башка рәвештә сатуга яисә читләштерүгә;
- җәмгыять уставында мондый мөмкинлек каралса, җәмгыятькә өлешне читләштерү юлы белән яисә законда каралган очракларда җәмгыять тарафыннан өлешне сатып алу таләбе белән җәмгыятьтән чыгу;

- җәмгыятьне гамәлдән чыгарган очракта, кредиторлар белән исәп-хисап ясаганнан соң калган мөлкәтнең бер өлешен яки аның бәясен алу;

- җәмгыятьтә катнашучыларның гомуми җыелышы карары буенча бирелгән, законда, Уставта каралган, җәмгыятьтә катнашучыларның барлык әгъзалары тарафыннан бер тавыштан кабул ителгән башка хокуклар.

Вәкил вәкаләтләре ышанычнамәдә беркетелә.

Көн тәртибендәге конкрет мәсьәлә буенча тавыш биргәндә, Вәкилнең позициясе район Башкарма комитеты җитәкчесе кул куйган (Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы белән килешенеп) язма күрсәтмәләрдә билгеләнә, аларның проекты район җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе тарафыннан әзерләнә.».

1) акцияләр буенча дивидендлар түләү мәсьәләләре буенча тавыш биргәндә вәкил позициясен формалаштырганда (капиталда катнашудан керемнәр) түбәндәге нигезләмәләргә таянып эш итәргә кирәк:

- хуҗалык җәмгыятенең чиста табышының кимендә 25 процентыннан да ким булмаган (финанс кертемнәрен яңадан бәяләүдән алынган керемнәрне исәпкә алмыйча) акцияләре буенча (капиталда катнашудан керемнәр) дивидендлар түләүгә җибәрү, әгәр муниципаль хокукый актларда башкача билгеләнмәгән булса;

- инвестиция проектларын финанслауга һәм башка максатларга, акцияләр буенча дивидендлар (капиталда катнашудан керемнәр) түләүгә бүлеп бирелмәгән чиста табышны юнәлдерү;

- инвестиция проектларының акционерлык җәмгыятендә билгеләнгән керемлелек таләпләренә туры килүе.

2) акцияләр буенча дивидендлар түләү буенча вәкил позициясен формалаштырганда (капиталда катнашудан керемнәр) анализ нигезендә карарлар кабул итү зарурлыгыннан чыгып эш итәргә:

- хуҗалык җәмгыятенең пландагы финанс күрсәткечләре, шул исәптән керем, уртача сроклы чорга (кимендә 3 ел);

- инвестицион проектларны финанслауга һәм башка максатларга хуҗалык җәмгыятенең чиста табышын юнәлтүнең икътисадый нәтиҗәлелеге;

- акцияләр буенча дивидендлар түләүгә юнәлдерелгән чиста табыш өлешенең (капиталда катнашудан керемнәр) хуҗалык җәмгыяте табышының факттагы кыйммәтенең аның план кыйммәтенә карата нисбәтеннән бәйлелеге.

3) Тавыш бирә торган барлык акцияләре Түбән Кама муниципаль районы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләрендә вәкилнең карарлары, район Башкарма комитеты җитәкчесе кул куйган беркетмә рәвешендә, хуҗалык җәмгыятенең бердәнбер акционеры карары белән рәсмиләштерелә.».

1.2 11.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.11 Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнарында вәкил еллык акционерлар (катнашучылар) гомуми җыелышы үткәрелгәннән соң 20 көн дәвамында район Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсенә, кушымта нигезендә, хуҗалык җәмгыяте идарәсе органнарындагы вәкил эшчәнлеге турында хисап тапшыра, шулай ук:

1) җәмгыять тарафыннан расланган бухгалтерлык хисаплылыгы күчермәләре һәм җәмгыятьнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге турында аналитик белешмәләр;

2) гамәлдәге законнар нигезендә җәмгыять эшчәнлеге турында бүтән мәгълүмат (җыелма бухгалтер хисабы (хуҗалык җәмгыятендә бүлендек һәм бәйле җәмгыятьләр булганда); хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышлары һәм директорлар советы (күзәтчелек советы) утырышлары беркетмәләре күчермәләре; аудитор һәм ревизия комиссиясе бәяләмәләре күчермәләре;

3) аңлатма язуы.

Районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе, чираттагы финанс елының 1 августыннан да соңга калмыйча, Түбән Кама муниципаль районы башлыгына һәм район Башкарма комитеты җитәкчесенә хуҗалык җәмгыятьләре акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышларының йомгаклау беркетмәләрен гомумиләштереп, хисап әзерли һәм тапшыра.».

1.3 11.14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Түбән Кама муниципаль районы акцияләрен (өлешләрен) хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларында файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын билгеләргә: акцияләрнең (өлешләрнең) чын бәясе артуы.».

1.4 «Хисап формасы» 1 нче кушымтасы өстәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

Э.Р.Долотказина

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2020 елның 23 мартындагы
26 номерлы карарына
1 кушымта

ХИСАП ФОРМАСЫ

## ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘКИЛЕНЕҢ ХУҖАЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ ИДАРӘСЕ ОРГАННАРЫНДА ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА ХИСАП

______________________________________________________________

(хуҗалык җәмгыяте исеме)

____________дан ______________________________________________кадәр

Түбән Кама муниципаль районы вәкиле:

______________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

| | |
|---|---|
| I бүлек. Гомуми мәгълүматлар | |
| Хуҗалык җәмгыяте турында | |
| Хуҗалык җәмгыятенең тулы исеме | |
| Дәүләт теркәве турында таныклык: | |
| Номеры | |
| Бирү датасы | |
| Урнашу урыны | |
| Почта адресы | |
| Тармагы | |
| Эшчәнлекнең төп төре | |
| Устав капиталы күләме | |
| Түбән Кама муниципаль районының хуҗалык җәмгыяте устав капиталында өлеше | |
| Ф.И.О. директора (генерального директора) хозяйственного общества или сведения об управляющей организации (управляющем) Хуҗалык җәмгыяте директоры (генераль директоры) Ф.И.О. яки идарәче оешма (идарәче) турында мәгълүматлар | |
| Телефон (факс) | |
| Электрон почта адресы | |
| Муниципаль берәмлек вәкилләре турында (бүлектә Түбән Кама муниципаль районының хуҗалык җәмгыяте идарәсе органнарында барлык вәкилләре турында мәгълүматлар китерелә) | |
| Вәкилнең Ф.И.О., эш урыны һәм вазыйфасы | |
| Вәкилнең вәкаләтләре вакыты | |

<table>
<tr><td colspan="5">Вәкилне (муниципаль хезмәткәрләр өчен) билгеләү турында муниципаль хокукый акт, датасы, номеры</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="5">Вәкил (муниципаль хезмәткәрләр булмаган физик затлар өчен) белән төзелгән шартнамә, датасы, номеры</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="5">Телефон (факс)</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="7">II бүлек. Хуҗалык җәмгыятьләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td colspan="5">Күрсәткеч атамасы</td><td colspan="2">Фактта ирешелгән күрсәткечнең кыйммәте</td></tr>
<tr><td colspan="5"></td><td>хисап чорына, мең сум.</td><td>узган елның шул ук чорына, мең сум.</td></tr>
<tr><td colspan="5">Сатудан кергән акча</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Табыш (югалтулар)</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Хисапланган дивидендлар (капиталда катнашудан керемнәр) суммасы</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Җирле бюджетка күчерелергә тиешле дивидендлар (капиталда катнашудан керемнәр) суммасы</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Җирле бюджетка күчерелгән дивидендлар (катнашудан кергән керемнәр) суммасы</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Җирле бюджетка күчерелергә тиешле дивидендлар (катнашудан кергән керемнәр) буенча бурычлар суммасы</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Җирле бюджетка дивидендлар (катнашудан керемнәр) күчерүне раслый торган документлар реквизитлары</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Кредит бурычлары</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Дебитор бурычы</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Чиста активлар бәясе</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="7">III бүлек. Хуҗалык җәмгыяте идарәсе органнарында Түбән Кама муниципаль районы вәкиленең эшчәнлеге турында мәгълүматлар</td></tr>
<tr><td colspan="7">Вәкилнең хуҗалык җәмгыятенең гомуми җыелышларында катнашуы</td></tr>
<tr><td>Үткәрү датасы</td><td>Краснодар шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиле Ф.И.О.</td><td>Ышанычнамә реквизитлары</td><td>Вәкаләтле органнан алынган күрсәтмәләр</td><td colspan="3">Көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча тавыш бирүдә вәкилнең позициясе</td></tr>
<tr><td colspan="7">Вәкилнең директорлар советы (күзәтчелек советы) утырышларында катнашуы</td></tr>
<tr><td>Үткәрү датасы</td><td>Түбән Кама муниципаль районы вәкиленең Ф.И.О.</td><td>Ышанычнамә реквизитлары</td><td>Вәкаләтле органнан алынган күрсәтмәләр</td><td colspan="3">Көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча тавыш бирүдә вәкилнең позициясе</td></tr>
<tr><td colspan="7">IV бүлек. Банкротлык билгеләре булу турында мәгълүмат</td></tr>
<tr><td colspan="5">Банкротлык билгеләре булу</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="5">Вакытында түләнмәгән бурыч: акчалата йөкләмәләр буенча</td><td colspan="2"></td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Мәҗбүри түләүләр буенча | |
| Хуҗалык җәмгыятен финанс яктан савыктыру максатларында, муниципаль берәмлек вәкиле тарафыннан кабул ителгән чаралар (банкротлык билгеләре булган очракта тутырыла) | |

Искәрмә:
Әлеге хисап белән бергә бирелә:

1) РФ гамәлдәге законнары белән билгеләнгән составтагы бухгалтер хисабы.
2) Җыелма бухгалтер хисабы (хуҗалык җәмгыятендә бүлендек һәм бәйле җәмгыятьләре булганда).
3) Хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучылар) гомуми җыелышлары һәм директорлар советы (күзәтчелек советы) утырышлары беркетмәләре күчермәләре.
4) Ревизия комиссиясе һәм аудитор бәяләмәләренең күчермәләре.
5) Җәмгыятьнең еллык хисабы.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина